РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«10» декабрь 2025 ел                                                  № 18

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 149 номерлы карарына (җирлек Советының

2020 елның 29 октябрендәге № 8, 2022 елның 27 октябрендәге № 140, 2022 елның 28 декабрендәге № 156, 2024 елның 27 июнендәге № 252, 2024 елның 26 декабрендәге № 288, 2025 елның 30 апрелендәге № 305 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 4 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладына күләме 16928,0 сум тәшкил итә»;

1.2. «Муниципаль район башлыгын, муниципаль районда үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисен акчалата бүләкләү күләмнәре» 2 нче кушымтасын яңа редакциядә кушымтада каралганча бәян итәргә.

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Бәркәтә авыл җирлеге Советының
2018 елның 24 апрелендәге
№149 карарына 2 нче кушымта

Кушымта
(Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2025 елның
10 декабрендәге №18 карары
редакциясендә)

Муниципаль район башлыгын, муниципаль районда үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы рәисен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 44 814 |
| Башлык урынбасары | 40 334 |
| Депутатлар | 21 977 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 18 674 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 40 334 |